СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д.5, с.
Ямбулатово,
422587

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 5 нче йорт, Ямбулат авылы,
422587

Тел.: (84379) 36-5-18 факс: (84379) 36-5-18

РЕШЕНИЕ КАРАР

28.10.2019г. с.Ямбулатово 61– 263

Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда
аерым нотариаль гамәлләр кылу турында

«Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге №226-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 16.1 статьясына, «Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында» (Россия Федерациясе ВС тарафыннан расланган 11.02.1993 N 4462-1) 2008 елның 15 гыйнварыннан җирлекләрнең җирле Администрация Башлыклары (Башкарма комитет җитәкчеләре) һәм нотариус җирлектә булмаган очракта, җирлекләрнең җирле үзидарәләренең махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары түбәндәге нотариаль гамәлләр кылырга хокуклы:

1) кучемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышаныч кәгазен расларга;

2) мирас мөлкәте исемлеген җитештерү юлы белән мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрергә;

3) документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең тугрылыгын раслау;

4) документларда имзаның чынлыгын дәлилләү;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда затлар турында белешмәләрне таныклыйлар;

6) гражданның исән булу фактын таныклыйлар;

7) тиешле җирлек яки муниципаль район территориясендә яшәүче күрү буенча инвалидның үз кулы белән имзасын факсималь күрсәтеп, тәңгәллеген расларга;

8) билгеләнгән урында гражданның урнашу фактын таныклыйлар;

9) фотода сурәтләнгән зат белән гражданинның тәңгәллеген таныклыйлар;

10) документлар тапшыру вакытын таныклыйлар;

11) документның кәгазьдә урнаштырылган тигезлеген раслыйлар;

12) документның кәгазьдә электрон документка тигезлеген таныклыйлар. Ямбулат авыл җирлегендә нотариус булмау сәбәпле, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 14.1 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты, 20 статьясындагы 4.1 өлеше, нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең 1 һәм 37 статьялары нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге җирле үзидарә органнары аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен 2008 елның 15 гыйнварыннан башкаруда катнашалар дип билгеләргә кирәк.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Башлыгы М.Н.Ахметзяновны нотариаль гамәлләр кылуга махсус вәкаләтле вазыйфаи зат итеп билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитетына аерым нотариаль гамәлләр башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүче чаралар күрергә.
4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында» 08.04.2008 № 24 – 102 карары үз көчен югалткан дип санарга

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге Башлыгы М.Н.Ахметзянов

Авыл җирлеге Башлыгы һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затына нотариаль гамәлләр кылуга махсус вәкаләтле вәкил, Югары Ослан муниципаль районы җирле администрациясе башлыгы һәм Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарәсенең нотариаль затына нотариаль гамәлләр кылуга махсус вәкаләтле вәкил турында мәгълүматлар

| № | Мәгълүматлар исеме | Мәгълүматлар |
|---|---|---|
| 1 | Нотариус булмаган җирлек яисә муниципаль район исеме | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге |
| 2 | Авыл җирлеге яки муниципаль район администрациясенең урнашкан урыны | 422587, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авылы, Центральная ур., 5 йорт |
| 3 | Җирле администрация Башлыгының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | Ахметзянов Марсель Наил улы |
| 4 | Җирле администрация Башлыгының белеме (белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе) турында белешмәләр | югары, КСХА, агроном |
| 5 | Телефон, факс (булганда), җирле администрациянең электрон почта адресы | 8 (84379) 36-5-18 / 8 (84379) 36-5-18<br>Marsel.Ahmetzyanov@tatar.ru |
| 6 | Затның җирле администрация Башлыгы вазыйфасын биләве турындагы документ реквизитлары (зат тарафыннан җирле администрация Башлыгы вазыйфасын биләү турындагы документның исеме, документның номеры һәм кабул итү датасы, кем тарафыннан бастырып чыгарылган) | «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Башлыгын сайлау турында» 17.09.2015 ел,№ 1-6 карары |
| 7 | Җирле администрация Башлыгының вәкаләтләре вакыты | 5 ел |
| 8 | Җирле үзидарәнең вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | Ахметзянов Марсель Наил улы |
| 9 | Җирле үзидарәнең вазыйфаи заты исеме | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Башлыгы |

| | | |
|---|---|---|
| 10 | Җирле үзидарә Башлыгының белеме (белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе) турында белешмәләр | югары, КСХА, агроном |
| 11 | Затның җирле үзидарә Башлыгы вазыйфасын биләве турындагы документ реквизитлары (зат тарафыннан җирле администрация Башлыгы вазыйфасын биләү турындагы документның исеме, документның номеры һәм кабул итү датасы, кем тарафыннан бастырып чыгарылган) | «Нотариаль гамәлләр кылуга махсус вәкаләтле вазыйфаи затны билгеләү турында» 09.01.2018 ел, № 2 боерык |
| 12 | Нотариаль гамәлләр кылуга җирле үзидарәнең вазыйфаи заты вәкаләтләре вакыты (булганда) | |

Җирле администрация Башлыгының имза үрнәкләре:

| | | |
|---|---|---|
| | | |

Җирле үзидарә Башлыгының имза үрнәкләре:

| | | |
|---|---|---|
| | | |

Россия Федерациясе Дәүләт гербы төшерелгән җирлек яки муниципаль район печате оттискы:

| | | |
|---|---|---|
| | | |